| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Менделеевский муниципальный район<br>Глава Мунайкинского сельского поселения | Татарстан Республикасы<br>Менделевск муниципаль районы<br>Монай авыл җирлеге башлыгы |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 7 01.11.2024 ел.

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең Монай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы “Монай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы
КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 11 ноябре 17.00 сәг. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең Монай торак пунктында, ТР, Менделеевск муниципаль районы, Монай торак пункты, Төзүчеләр урамы, 12 йорт адресы буенча урнашкан Монай авыл мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенында түбәндәге сорауны расларга:
2026 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең Монай торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы тыл ветераннарыннан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан тыш, кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

«1) Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү"»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Монай авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлеге башлыгы ____________ Р.М.Кириллов
(имза) (имзаны киңәйтү)